ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«22» декабрь 2021 ел

№ 2264

**«Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет төзү турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварындагы 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Үсеп килүче буынны хәрби-патриотик тәрбияләү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру, патриотик тәрбия бирүче структуралар эшчәнлеген координацияләү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет төзү турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварындагы 33 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"22" 12 2021ел, № 2264*
*карарына кушымта*

**Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет составы**

| | |
|---|---|
| Мөхәрәмов Р.Р. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, координацион совет рәисе; |
| Вафина Э.Ш. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, координацион совет рәисе урынбасары; |
| Борһанов А.Ә. | - Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Арча һәм Әтнә районында бүлек башлыгы, координацион совет рәисе урынбасары (килешү нигезендә); |
| Габделгазизов И.Н. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, координацион совет секретаре. |

***Координацион совет әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Мөхәмәдияров Р.Д. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ башлыгы; |
| Әюпов И.И. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәдәният идарәсе" МУ башлыгы; |
| Баһавиев А.Р. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Зәйнуллин И.М. | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Форпост» үзәге» МБУ җитәкчесе |

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"22" 12 2021ел, № 2264*
*карарына 1 нче кушымта*

**Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет (алга таба-Совет) яшь буынны хәрби-патриотик тәрбияләүдә оешмаларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, хәрби һәм иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген координацияләү максатыннан төзелә.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының патриотик тәрбия өлкәсендәге законнар һәм башка норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Советның төп бурычлары

Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү, яшьләрнең Ватанны саклауга физик һәм әхлакый әзерлеген ныгыту.

2.2. Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча перспективалы планнар һәм программалар эшләү, әлеге юнәлештә эшне камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.3. Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча бүлекләр һәм структур бүлекчәләр, хәрби һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү.

2.4. Үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү буенча эш тәҗрибәсенә яңа алымнар, формалар һәм ысуллар кертү.

3. Советның вәкаләтләре

Совет түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча программаларны һәм чараларны гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карый.

3.2. Хәрби һәм иҗтимагый оешмаларның бүлек һәм структур бүлекчәләреннән патриотик тәрбия өлкәсендәге эшчәнлекләре турында материаллар һәм мәгълүмат соратып ала.

3.3. Патриотик тәрбия эшенең барышы турында структур бүлекчәләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар вәкилләренең чыгышарын тыңлый.

3.4. Вакытлы эшче төркемнәр төзи, Совет компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тиешле белгечләрне җәлеп итә.

3.5. Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүдә ирешкән уңышлары өчен катнашучыларны бүләкләү һәм бәяләү турында Арча муниципаль районы башлыгына тәкъдимнәр кертә.

4. Совет эшен оештыру

4.1. Совет рәисе булып Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тора.

4.2. Совет составы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

4.3. Фикер алышкан мәсьәләләрне һәрьяклап карауны тәэмин итү өчен Совет утырышына Арча муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы төрле оешма вәкилләре чакырыла ала.

4.4. Совет эшчәнлеген эш планы нигезендә гамәлгә ашыра, ул Совет утырышында кабул ителә һәм Совет рәисе тарафыннан раслана.

4.5. Совет утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы булып санала.

4.6. Совет утырышы кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

4.7. Карарлар ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен Совет утырышында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

4.8. Совет утырышлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, алар рәис һәм секретарь тарафыннан имзалана.